КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 26 сентябрь г.Казань № 878

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бөлгенлек процедураларының һәм арбитраж идарәчеләр эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру буенча кайбер чаралар турында» 2007 ел, 3 сентябрь, 432 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында бөлгенлек процедураларының һәм арбитраж идарәчеләр эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру мәсьәләләре буенча башкарма хакимият органнары һәм җирле үзидарә органнарының үзара хезмәттәшлеге буенча эшче төркем составына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бөлгенлек процедураларының һәм арбитраж идарәчеләр эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру буенча кайбер чаралар турында» 2007 ел, 3 сентябрь, 432 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 8 октябрь, 542 нче; 2008 ел, 7 июль, 467 нче; 2008 ел, 17 ноябрь, 820 нче, 2008 ел, 24 ноябрь, 829 нчы, 2010 ел, 22 июль, 580 нче; 2012 ел, 11 февраль, 107 нче; 2012 ел, 30 июль, 647 нче; 2012 ел, 27 ноябрь, 1034 нче; 2014 ел, 29 март, 200 нче; 2014 ел, 17 ноябрь, 882 нче; 2015 ел, 22 июль, 537 нче; 2015 ел, 30 июль, 551 нче; 2017 ел, 18 гыйнвар, 12 нче; 2017 ел, 29 декабрь, 1107 нче; 2018 ел, 4 октябрь, 905 нче; 2018 ел, 26 ноябрь, 1051 нче; 2019 ел, 9 сентябрь, 808 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында бөлгенлек процедураларының һәм арбитраж идарәчеләр эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру мәсьәләләре буенча башкарма хакимият органнары һәм җирле үзидарә органнарының үзара хезмәттәшлеге буенча эшче төркем составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

эшче төркем составыннан Ә.Ф.Закировны чыгарырга;

эшче төркем составына Федераль суд приставлары хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары Эльвира Рәшид кызы Лабашованы (килешү буенча) кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин